| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
|---|---|
| ***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*** | ***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*** |
| ***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | ***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

9 ноябрь 2016 ел № 3-13

**«Җир салымы турында» 2016 елның 18 октябрендәге 1-12 номерлы Буа шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1. «Җир салымы турында» Буа шәһәр Советының 2016 елның 18 октябрендәге 1-12 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Салым ставкалары» 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 сатья. Салым ставкалары

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,201%-ы;

2) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,201%ы;

3) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составына кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы зоналары составындагы җирләргә карата кадастр бәясенең 0,3 проценты;

4) оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә киртәләнгән җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,3 проценты;

5) башка җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясеннән 1,25 % ».

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгы А.К. Айзетуллов